ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 август 2019 ел № 4427

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ санлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 елның 7 июнендәге 432 нче карары, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамәсе, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук аны «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның
28 августындагы
4427 нче карарына
кушымта

## Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: Яр Чаллы шәһәренең Комсомол, Үзәк һәм Автозавод районнары территорияләрендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ физик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Муниципаль хезмәтне күрсәтүчеләр – Комсомол, Үзәк һәм Автозавод районнары хакимиятләре (алга таба – район хакимиятләре).

1.3.1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының урнашкан урыны: Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Район хакимиятләре урнашкан урын: Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре:

Комсомол районы – ГЭС, 8/7 йорты, 5, 7 кабинетлар.
Үзәк районы – Яңа шәһәр, 3/08 йорты, 103 кабинет.
Автозавод районы – Яңа шәһәр, 49/09 йорты, 101 кабинет.
Район хакимиятләренең эш графигы:
Дүшәмбе – җомга 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр.
Шимбә, якшәмбе – ял көннәре.
12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр – төшке ял вакыты.
Район хакимиятләренең белешмә телефоннары:
Комсомол районы – 70-45-46.
Үзәк районы – 47-55-72.
Автозавод районы – 56-74-16.

Хакимиятләр бинасына керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: www.nabchelny.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет кабинетларында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтында: www.nabchelny.ru;

3) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) район хакимиятләрендә:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) – кәгазь йөрткечтә почта аша, электрон рәвештә электрон почта аша (http://www.gosuslugi.ru/).

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат район хакимиятләре белгечләре тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, район хакимиятләре биналарында урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ санлы Торак кодексы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 03.01.2005, №1, (1 бүлек), ст. 14) (алга таба – РФ ТК);

2) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (РФ законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, ст. 4179) (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон);

3) «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, 20.03.2015, №38) (алга таба – 13-ЗРТ ТР Законы);

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2018 елның 7 июнендәге 432 нче карары (Татарстан Республикасы

законнар җыентыгы, 19.06.2018, №45, ст.1638) (алга таба – ТР Министрлар Кабинетының 07.06.2018 №432 карары);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст. 3822);

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, 10.12.2005, №№235-237, 30.12.2005, №№249-250);

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Совктының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы («Челнинские известия», 10.12.2005, №235-237; 30.12.2005, №249-250) (алга таба – Устав);

6) Башкарма комитетның 2008 елның 31 декабрендәге 1422 нче боерыгы белән расланган Комсомол, Үзәк, Автозавод районнары хакимиятләре турында нигезнамәләр (Район хакимияте турында нигезнамә);

7) Башкарма комитетның 2007 елның 16 июлендәге 754 нче боерыгы белән расланган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

8) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эш регламенты (алга таба – Эш регламенты).

1.5. Әлеге Регламентта социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алуны федераль норматив хокукый актлар һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда, гражданнарны торак белән тәэмин итү дип аңларга кирәк.

Торак хокуклары объектлары – социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары:

торак йорт, торак йортның өлеше – бүлмәләрдән торган индивидуаль-аерым бина, шулай ук андый бинада гражданнарның көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче файдаланудагы бүлмәләр;

фатир, фатирның өлеше – күп фатирлы йортта гомуми файдаланудагы бүлмәләргә турыдан-туры керә алу мөмкинлеген бирүче һәм бер яки берничә бүлмәдән торган структур-аерымланган бүлмә, шулай ук андый аерымланган бүлмәдә яшәү белән бәйле рәвештә, гражданнарның көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче файдаланудагы бүлмәләр;

бүлмә – гражданнарның торак йортта яки фатирда турыдан-туры яшәү урыны сыйфатында файдалану өчен билгеләнгән торак йортның яки фатирның бер өлеше.

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза дип аңларга кирәк (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсендәге 2 пункт).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Исеме | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу | РФ ТКның 91.13 маддәсе;<br>13-ЗРТ санлы ТР Законы |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органының исеме | Район хакимиятләре йөзендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | шәһәр Уставы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Башкарма комитетның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алу яисә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алуны кире кагу турындагы карары | РФ ТКның 91.13 маддәсе;<br>13-ЗРТ санлы ТР Законы |
| 2.4. Күрсәтү срогы | Гаризаны теркәгән вакыттан башлап 30 эш көне эчендә | РФ ТКның 91.13 маддәсе; |

| | | |
|---|---|---|
| | | 13-ЗРТ санлы ТР Законы |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында каралган форма буенча гариза;<br>2) гражданның һәм аның белән даими бергә яшәүче гаилә әгъзаларының паспортларының яки шәхесләрен таныклаучы документның күчермәләре;<br>3) гражданның гаилә составы турындагы документлар күчермәсе (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану һәм башкалар турында суд карары);<br>4) гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының биләгән торак урыныннан файдалануга хокукын раслаучы документ күчермәләре (килешү, ордер, торак урыны бирелү турында карар һәм башка документлар) – 1999 елның 31 декабренә кадәр<br>5) 1999 елның 31 декабренә кадәр дәүләт теркәвен гамәлгә ашырган дәүләт теркәве органыннан, даими яшәү урыны буенча гаиләнең гариза бирүче һәр юридик хокуклы әгъзасының торак урынына милек хокукы булу яки булмавы турында мәгълүматлар;<br>6) граждан хезмәт эшчәнлеге алып барган очракта – эш | ТР Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| | урынышнан аның фактта түләнгән акчалары (законнар нигезендә барлык салымнарны һәм җыемнарны түләгәннән соңгы) күрсәтелгән белешмә;<br>7) барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан, дәүләтнең бюджеттан тыш фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр алу (алмау) турында белешмә;<br>8) уку йортында укыган очракта – стипендия алу (алмау) турында белешмә;<br>9) эшсез гражданнар өчен – эшсезлек турында пособие алу (алмау) турында белешмә;<br>10) гражданның яки аның гаилә әгъзаларының вакытлыча хезмәткә яраксызлыгы буенча пособие алуы (алмавы) турында белешмә;<br>11) 1 яшькә кадәр балалары булган гражданнар өчен – йөклелек һәм бала табу буенча пособие, шулай ук йөклелекнең иртә срокларында медицина оешмаларына исәпкә баскан хатыннарга бер тапкыр түләнә торган пособие алу (алмау) турында белешмә;<br>12) 3 яшькә кадәр балалары булган гражданнар өчен – балага айлык пособие алу (алмау) турында белешмә;<br>13) хәрби хезмәт үтүченең хатыны (ире) гаиләсендә – үз составында хәрби хезмәткәләр һәм аларның гаиләләре булган | |

| | | |
|---|---|---|
| | гражданнар өчен айлык пособие алу (алмау) турында белешмә;<br>14) производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү – производствода бәхетсезлек очраклары һәм һөнәри авыру кичергән гражданнар өчен айлык иминият түләүләре алу (алмау) турында белешмә;<br>15) №13-ЗРТ санлы ТР Законының 6 маддәсендә каралган башка алынган керемнәр турында белешмә;<br>16) милектә транспорт чарасы булу (яки булмау) турында белешмә;<br>17) милектә су транспорты чарасы (яхталар, кече суднолар, моторлы көймәләр һ.б) булу (яки булмау) турында белешмә;<br>18) күчемсез милек объектының кадастр бәясе турында белешмә – милкендә торак урыннар, җир участоклары, дачалар, гаражлар һәм башка төзелешләр, биналар һәм корылмалар булган гражданнар өчен;<br>19) әлеге Регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында гариза;<br>20) ышаныч язуы – граждан һәм (яки) аның гаилә әгъзалары исеменнән | |

| | | |
|---|---|---|
| | ышанычлы зат эш иткән очракта. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән сату-алу эшләре бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объектлары булган (булучы) аерым затның күчемсез милек объектларына хокуклары турында өземтә;<br>2) Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән сату-алу эшләре бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (анда күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем ала алырлык мәгълүматлар булырга тиеш);<br>3) Күчемсез милеккә хокук һәм аның белән сату-алу эшләре бердәм дәүләт реестрыннан хокукларның күчемсез милек объектына күчүе турында өземтә;<br>4) үлемне дәүләт теркәве турында мәгълүмат;<br>5) гражданның яшәү урыны буенча теркәлүе турында мәгълүмат;<br>6) торак бинада яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарның санын раслый торган мәгълүмат. | |
| 2.7. Дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнары һәм аларның муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актларда каралганча, килешену | 1) Башкарма комитетның район хакимиятләре;<br>2) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе; | |

| | | |
|---|---|---|
| таләп ителә торган, муниципаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы башкарма органның структур бүлекчәләре исемлеге | 3) Башкарма комитетның хокук идарәсе;<br>4) Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе;<br>5) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру;<br>2) гариза тексты укырлык түгел;<br>3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>1) тапшырылган документларда социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗларны исәптә тотуга гражданның хокукы расланмау, шул исәптән:<br>- гариза бирүченең Россия Федерациясе гражданы булмавы (Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкача каралмаган булса),<br>- 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ санлы ТР Законында билгеләнгән тәртиптә гражданның аз керемле дип танылуы яки гражданны аз | РФ ТК;<br>13-ЗРТ ТР Законы<br>ТР Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 нче карары |

| | | |
|---|---|---|
| | керемле дип тану өчен нигезләрнең булуы,<br>- гражданның һәм аның белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзалары керемнәренең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтенең бәясе 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ санлы ТР Законының 5 маддәсе нигезендә билгеләнгән максималь күләмнән артмавы;<br>2) торак шартларының начараюына китергән гамәлләр эшләнү көненнән соңгы срокның (биш ел) чыкмавы;<br>3) дәүләт хакимияте органыннан, җирле үзидарә органыннан яисә дәүләт хакимиятенең ведомстводагы органыннан яки оешманың җирле үзидарә органыннан ведомствоара запроска муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын дәлилли торган җавапның керүе, әгәр тиешле документ гариза бирүченең үз инициативасы буенча бирелмәгән булса;<br>4) Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларның бирелмәве | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы һәм башка түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алуның тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалануга чират булганда – 15 минут.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан да артмаска тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, андый хезмәтләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикле инвалидларны да истә тотып. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәттән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәттән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре:<br>1) документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) муниципаль хезмәттән файдалануның срогын үтәү;<br>3) муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә.<br>3) муниципаль хезмәткәрләрнең Административ регламентны бозу гамәлләренә прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә күрсәтелгәндә (алга таба – КФҮ) консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ хезмәткәрләре башкара. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон рәвештә файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирү законда каралганча электрон рәвештә бирелгән очракта, гариза Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша бирелә | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) материалларны карау;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен, гариза бирүче район хакимиятенә шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Район хакимияте белгече гариза бирүчегә тапшырыла торган документларның составы, формасы, муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультация бирә, һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутырырга ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче гаризасын шәхсән яки вәкиле аша язмача бирә һәм әлеге Регламентның 2.5. пункты нигезендә аны район хакимиятенә тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза район хакимиятенә электрон почта аша яки Интернет-кабул итү аша электрон рәвештә җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гариза билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

3.3.2. Гаризалар кабул итүче район хакимияте белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5. пунктында каралган документларның булуын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә.

Кимчелекләр булмаган очракта, район хакимияте белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы гражданнарны исәпкә алу турындагы гаризаларны кабул итә һәм шундый гаризаларны әлеге Регламентка 4 нче кушымтадагы форма буенча алып барыла торган теркәү кенәгәсендә терки;

гариза бирүчегә, әлеге Регламентка 5 нче кушымтадагы форма буенча аннан гариза һәм аңа беркетелгән документлар алынуы, аларның исемлеген һәм алу датасын күрсәтеп, расписка бирә.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында каралганча, документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләр булган очракта, документлар кабул итүче район хакимияте белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм аңа документларны кабул итүне кире кагу өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Район хакимияте белгече ведомствоара электрон эшчәнлек системасы аша күчемсез милеккә хокук һәм аның белән сату-алу эшләре бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез милек объектлары булган (булучы) аерым затның (һәр гаилә әгъзасына) күчемсез милек объектларына

хокуклары турында өземтә бирелү һәм хокукның күчемсез милек объектына күчүе турында өземтә бирелү турындагы запросларны җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүмат куючы белгечләр, ведомствоара электрон эшчәнлек системасы аша кергән запрос нигезендә, соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында хәбәр итү кәгазе җибәрәләр (алга таба – кире кагу турында хәбәр итү кәгазе).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар ведомствоара запрос документ яки мәгълүмат бирүче органга яки оешмага кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм аны җибәрүнең федераль законнар, Россия Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителгән башка сроклар каралмаган булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: кире кагу турында район хакимиятенә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә кире кагу турында хәбәр итү кәгазе.

3.5. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Район хакимияте белгече норматив хокукый база таләпләрен исәпкә алып гариза һәм документларны карый.

Әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен нигезләр булмаган очракта, район хакимияте белгече социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алу турында карар проекты әзерли һәм аны килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

1) Башкарма комитетның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алу турында килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрелгән карар проекты;

2) Башкарма комитетның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алуны кире кагу турында килешенү өчен район хакимияте Башлыгына җибәрелгән карар проекты.

3.5.2. Район хакимияте Башлыгы документларны карап тикшерә һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алуга

яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын килешенү хакында карар кабул итә (алга таба – исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар).

Исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында килешенгән карар проектын район хакимияте белгече имзалау өчен Башкарма комитетның Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы урынбасарына җибәрә (алга таба – идарә башлыгы урынбасары).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

Башкарма комитетның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алу турында килешенү өчен идарә башлыгы урынбасарына җибәрелгән карар проекты;

Башкарма комитетның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алуны кире кагу турында килешенү өчен идарә башлыгы урынбасарына җибәрелгән карар проекты.

Идарә башлыгы урынбасары документларны карап тикшерә һәм социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын килешенү хакында карар кабул итә һәм аны килешенү өчен Башкарма комитетның Хокук идарәсенә җибәрә (алга таба – Хокук идарәсе).

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, идарә башлыгы урынбасары исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектына кимчелек турында күрсәтмә әзерли һәм аны, әлеге кимчелекне төзәтү өчен район хакимияте белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

Исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән килешенгән карар проекты, яисә исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында район хакимияте белгеченә җибәрелгән карар проектына кимчелек турындагы күрсәтмә.

3.5.4. Идарә башлыгы урынбасары тарафыннан исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карар проектына кимчелек төзәтелгән очракта, район хакимияте белгече идарә башлыгы урынбасарының исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карар проекты буенча кимчелекне төзәтә һәм алга таба килешенү өчен аны идарә башлыгы урынбасарына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы төзәтелгән һәм килешенү өчен идарә башлыгы урынбасарына җибәрелгән карар проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карар проектын карап тикшерә, аны килешенә һәм алга таба килешенү өчен Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Хокук идарәсе исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектына кимчелек турында күрсәтмә әзерли һәм аны, әлеге кимчелекне төзәтү өчен район хакимияте белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын килешенү өчен Хокук идарәсенә җибәргән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында килешенү өчен Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесенә җибәрелгән, килешенгән карар проекты, яисә район хакимияте белгеченә төзәтү өчен җибәрелгән кимчелек.

3.5.6. Хокук идарәсе тарафыннан исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карар проектына кимчелек хакында күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, район хакимияте белгече исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карар проекты буенча кимчелекне төзәтә һәм алга таба килешенү өчен аны Хокук идарәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында төзәтелгән, Хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.7.5. Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Башкарма комитетның исәпкә алу яки исәпкә алуны кагу турында карар проектын карап тикшерә, аны килешенә һәм район хакимияте белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында төзәтелгән, район хакимияте белгеченә җибәрелгән карар проекты.

3.5.8. Район хакимияте белгече исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында килешенгән карар проектын Башкарма комитетның Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә (алга таба – Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе).

3.5.4, 3.5.6 – 3.5.8, пунктларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында килешенгән, Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.9. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе:

1) исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын соңгы вариантта тикшерә;

2) вазыйфаи затларның кирәкле визалары булуын (булмавын), карар проектын тарату реестры кәгазен тикшерә;

3) исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын Башкарма комитет бланкында бастыра;

исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.10. Башкарма комитет Җитәкчесе исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проектын имзалый һәм аны Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы имзаланган, Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.5.11.Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гамәлгә ашыра:

1) исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы имзаланган карар проектын терки;

2) исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карарның күчермәләрен карар проектын тарату реестры нигезендә җибәрә;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе:

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында теркәлгән һәм район хакимияте белгеченә җибәрелгән карар.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Район хакимияте белгече исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карар күчермәсенең бер нөсхәсен гариза бирүчегә шәхсән тапшыра, икенчесен район хакимиятендә исәп делосында саклау өчен калдыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар имзаланган көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яки гаризада күрсәтелгән адрес буенча җибәрелгән исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турындагы карарның күчермәсе.

3.7. Гражданнарны исәпкә алу гариза бирү вакытыннан һәм кирәкле документлардан чыгып, чират тәртибендә гамәлгә ашырыла. Гражданнарны исәпкә алу вакыты булып, гариза һәм документларны бирү вакыты, 2005 елның 1 мартына кадәр торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатындагы затны исәпкә алу вакыты дип, күрсәтелгән гражданнарны шундый исәпкә алу вакыты санала.

3.7.1. Исәпкә алынган һәр гражданга исәп делосы формалаштырыла, анда аны исәпкә алу өчен нигез булып хезмәт итәрлек барлык документлар да булырга тиеш.

Гражданның исәп делосына номер бирелә, ул әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында каралган форма буенча алып барыла торган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алу турында гражданнарның гаризаларын теркәү кенәгәсендәге (алга таба – исәп кенәгәсе) тәртип санына туры килергә тиеш. Исәп делосында документларга номер куела, опись ясала һәм кергән датасы буенча хронологик тәртиптә урнаштырыла. Исәп делосына үзгәрешләр гражданнарның документлардагы мәгълүматлары турында Башкарма комитетның тиешле карарын кабул итү юлы белән кертелә.

3.7.2. Исәпкә алынган гражданнар социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары бирелүгә чират исемлегенә кертеләләр (алга таба – исәп исемлеге).

3.7.3. Гаризаларны теркәү кенәгәсе һәм исәп кенәгәсе номерланган, шнур белән тегелгән һәм аңа район хакимиятенең мөһере сугылган булырга тиеш. Гаризаларны теркәү кенәгәсе һәм исәп кенәгәсендә чистартулар булмаска тиеш. Тиешле документлар нигезендә кертелгән төзәтүләр һәм үзгәрешләр исәпкә алу буенча җаваплылык йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан раслана.

Район хакимияте торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарның исәп кенәгәләрен һәм исәп делоларын тиешенчә саклауны тәэмин итә. Башкарма комитетның Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарның исәп исемлеген тиешенчә саклауны тәэмин итә. Күрсәтелгән документлар торак урын бирелгәннән соң 10 ел саклана.

3.7.4. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алынган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтләренең бәясен, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә хокукларын раслау максатында, 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ санлы ТР Законында билгеләнгән тәртиптә район хакимияте ел саен 1 гыйнвардан 1 майга кадәрге чорда яңадан бәяли. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алынган гражданнарның керемнәрен һәм мөлкәтләренең бәясен яңадан бәяләү үткәрү өчен, гражданнар кирәкле документларны үз инициативасы буенча тапшырмаган очракта, район хакимияте әлеге Регламентның 2.5 һәм 2.6. пунктларында күрсәтелгән документларны 1 апрельгә кадәр срокта ведомствоара эшчәнлек тәртибендәге запрос буенча ала.

Әгәр яңадан бәяләү үткәрү барышында социаль файдаланудагы гражданның торак урыннары бирелүгә мохтаҗлык статусын раслау өчен

нигезләрнең юклыгы билгеле булса, район хакимиятләре, запрос буенча әлеге Регламентның 2.5 һәм 2.6. пунктларында күрсәтелгән документларның тулы комплектын тапшырган һәм (яки) алган көннән башлап утыз көннән дә соңга калмыйча, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданны исәптән төшерү турында Башкарма комитетның карар проектын әзерли. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданны исәптән төшерү турында карар проекты, күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә һәм гражданга җибәрелә.

3.8. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү

3.8.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.4 - 3.6. пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәтнең нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формасы

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, шикаятьләрне карап тикшерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерү үткәрүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килешенү. Тикшерүнең нәтиҗәсе проектларны визалау була.

2) билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки бер еллык планнары нигезендә тормышка ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр дә каралырга мөмкин (комплексны тикшерүләр), яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә эш итүләргә контрольне гамәлгә ашыру һәм карарлар кабул итү максатларында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2 Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы район хакимиятләре Башлыклары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3 Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Башкарма комитетның структура бүлекчәләре турындагы нигезләмәләре һәм вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4 Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре вакытында каралмаган өчен җаваплылык тота.

Район хакимиятләре Башлыклары элеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплылык тоталар.

Вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышындагы карарлары һәм эш итүләре (итмәүләре) өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тоталар.

## 5. Башкарма комитет, аның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләре, шулай ук КФҮнең, КФҮ белгечләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләре карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы күпфункцияле үзәк белгечләренә, күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючыга шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәүнең срогы бозылу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтүнең срогы бозылу. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче КФҮнең, КФҮ белгеченең карарларына һәм эш итүләренә (итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шул очракта шикаять бирә ала, әгәр дә шикаять бирелә торган КФҮ гә 210-ФЗ санлы Федераль законның 1.3 бүлегендәге 16 маддәдә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат, эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль

берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче КФҮнең, КФҮ белгеченең карарларына һәм эш итүләренә (итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шул очракта шикаять бирә ала, әгәр дә шикаять бирелә торган КФҮ гә 210-ФЗ санлы Федераль законның 1.3 бүлегендәге 16 маддәдә билгеләгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылу. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче КФҮнең, КФҮ белгеченең карарларына һәм эш итүләренә (итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шул очракта шикаять бирә ала, әгәр дә шикаять бирелә торган КФҮ гә 210-ФЗ санлы Федераль законның 1.3 бүлегендәге 16 маддәдә билгеләгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче КФҮнең, КФҮ белгеченең карарларына һәм эш итүләренә (итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шул очракта шикаять бирә ала, әгәр дә шикаять бирелә торган КФҮ гә 210-ФЗ санлы Федераль законның 1.3 бүлегендәге 16 маддәдә билгеләгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән булса;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче КФҮнең, КФҮ белгеченең карарларына һәм эш итүләренә (итмәүләренә) судка кадәр (судтан

тыш) шул очракта шикаять бирә ала, әгәр дә шикаять бирелә торган КФҮ гә 210-ФЗ санлы Федераль законның 1.3 бүлегендәге 16 маддәдә билгеләгән тәртиптә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү функциясе йөкләнгән булса.

5.2. Шикаять язмача кәгазь йөрткечтә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, күпфункцияле үзәкнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять гариза бирүче яисә аның вәкаләтле заты тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылса, гариза бирүчегә әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелсә, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының, шулай ук КФҮнең, КФҮ хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе

______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

______________________________________,
___________________________ яшәүче
(яшәү урыны адресы)

______________________________________,
паспорт _______________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________________,
телефон номеры
______________________________________

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарынанаем килешүләре буенча торак бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу турында
ГАРИЗА

Мине, _______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

_____________________________________________________________________,
(туган көне)

һәм минем гаилә әгъзаларын (булганда) ___________________________________
(туганлык мөнәсәбәтләренең дәрәҗәсе,

_____________________________________________________________________,
фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

_____________________________________________________________________,
туган көне, паспорт мәгълүматлары)

социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак бирелүгә мохтаҗ гражданнар исәбенә алуны сорыйм (алга таба – исәпкә алу).

Әлеге гариза белән үземнең һәм гаилә әгъзаларымның (булганда) Россия гражданнары булуыбызны, Россия Федерациясенең Торак кодексы билгеләгән нигезләрдә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем

килешүләре буенча торак бирелүгә мохтаҗ гражданнар булуыбызны раслыйм, шулай ук:

минем салым салына торган керемем һәм минем белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәре һәм безнең милкебезнең бәясе Татарстан Республикасының «Гражданнарның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак бирелү хокукларын тормышка ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ санлы Законының 5 маддәсе нигезендә билгеләнгән максималь күләмнән артмавын раслыйм;

«Гражданнарның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак бирелү хокукларын тормышка ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ЗРТ санлы Законында билгеләнгән тәртиптә, мин һәм минем гаилә әгъзалары Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан аз керемле булып танылмаган һәм танылган булырга нигезләр юк.

Мине һәм минем гаилә әгъзаларын исәпкә алганнан соң, мин биргән мәгълүматларның дөрес түгеллеге ачыкланган очракта, минем һәм минем гаилә әгъзаларының исәптән төшерелүе миңа мәгълүм.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты тарафыннан мин һәм минем балигъ булмаган гаилә әгъзалары салым, таможня һәм башка органнардагы керемнәр һәм милек турындагы мәгълүматларны тикшерүгә ризалык бирәбез. Шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә һәм бирүгә ризалык турында гаризамны терким.

Гаризага теркәлгән документлар:

1. ____________________________________________
(документның исеме, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

2. ____________________________________________
(документның исеме, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

3. ____________________________________________
(документның исеме, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

4. ____________________________________________
(документның исеме, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

5. ____________________________________________
(документның исеме, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

Гариза бирүче __________________

____________________________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

Гаилә әгъзалары (булганда):

__________________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

__________________ ______________________________
(имза) (фамилиясе. исеме, атасының исеме (булганда))

__________________ ______________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

«____» _________________ 20___ел.

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе

______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

______________________________,

______________________________
(яшәү урыны адресы)

______________________________яшәүче,

паспорты______________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

______________________________,

телефон номеры

______________________________

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитетында шәхси мәгълүматларны
эшкәртүгә риза булу турында
ГАРИЗА

Мин,

______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

Шәхесемне таныклаучы документ ______________________________________________
серия _______ № _____________, бирелгән ______________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________,

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль законның 9 маддәсе нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Россия Федерациясенең Торак кодексы нигезендә мине исәпкә алу өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кирәкле шәхси мәгълүматларымны һәм башка мәгълүматларны эшкәртүгә һәм файдалануга рөхсәт бирәм

Мин Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына мине исәпкә алу буенча минем хокукларымны гамәлгә ашыру өчен мине исәпкә алу өчен кирәкле вакыт аралыгында дәгъва срогының вакыты чыкканчы шәхси мәгълүматларымны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, дөресләү (яңарту, үзгәртү), тапшыру һәм файдалануга ризалыгымны бирәм.

Мин Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан мине исәпкә алу һәм законлы хокукларымны һәм мәнфәгатьләремне тәэмин итү максатында шәхси мәгълүматларымны өченче затлардан алуга һәм өченче затларга бирүгә каршы түгел.

Мин түбәндәге мәгълүматларымны саклауга, эшкәртүгә һәм тапшыруга ризалык бирәм.

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне.

2. Теркәлү, вакытлыча теркәлү, фактта яшәү урынының адресы, телефоннары.

3. Шәхесне таныклаучы документ (сериясе, номеры, бирү вакыты, документ биргән органның исеме).

4. Россия Федерациясенең Торак кодексы нигезендә мине исәпкә алу өчен кирәкле башка шәхси мәгълүматлар.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ санлы Федераль законда каралган очракларда, әлеге гаризаны кире алу Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына гариза бирү нигезендә башкарыла.

Шәхси мәгълүматлар субъекты

____________________ ________________________________________________________

(имза) ( фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

____________________ ___________________ __________________________________________________

(шәхси мәгълүматлар субъектының ризалыгын алучы операторның вазыйфасы (имза)
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

«____» _________________ 20___ел.

Социаль файдаланудагы торак
фондының торак урыннарына
наем килешүләре буенча торак
урыннары бирелүгә мохтаҗ
гражданнарны исәпкә алу
буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ
регламентына
3 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча
гамәлләр эзлеклелегенең
блок-схемасы




Мәгълүмат куючы белгечләр запросны эшкәртәләр
Мәгълүматлар бирә
Әйе
Юк
Мәгълүмат куючы белгечләр мәгълүматлар бирә
Документлар яки мәгълүматлар
Мәгълүмат куючы белгеч кире кагу турында хәбәр итү кәгазе әзерли
Кире кагу турында хәбәр итү кәгазе
Район хакимияте белгече исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында карар проекты әзерли һәм аны район хакимияте Башлыгына килешенүгә җибәрә
Исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында район хакимияте башлыгына килешенүгә җибәрелгән карар проекты
Район хакимияте Башлыгы карар проектын килешенә һәм аны идарә башлыгы урынбасарына килешенүгә җибәрә
Идарә башлыгы урынбасарына килешенүгә җибәрелгән карар проекты
Идарә башлыгы урынбасары карар проектын карый, килешенә, аны Хокук идарәсенә килешенүгә җибәрә яки район хакимияте белгеченә кимчелекләрне төзәтүгә күрсәтмә җибәрә
Исәпкә алу яки исәпкә алуны кире кагу турында район хакимияте Башлыгына җибәрелгән карар проекты
Район хакимияте белгече кимчелекләрне төзәтә һәм карар проектын идарә башлыгы урынбасарына килешенүгә җибәрә
Башкарма комитетның Хокук идарәсе карар проектын карый, килешенә, Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яки район хакимияте белгеченә кимчелекләрне төзәтүгә күрсәтмә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты
Район хакимияте белгече кимчелекләрне төзәтә һәм аны Хокук идарәсенә җибәрә


Башкарма комитет Җитәкчесе проектны килешенә һәм район хакимияте белгеченә җибәрә
Район хакимияте белгеченә җибәрелгән килешенгән карар проекты
Район хакимияте белгече карар проектын Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән килешенгән карар проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе карар проектын тикшерә, бланкта бастыра һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә
Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар проекты
Башкарма комитет Җитәкчесе карар проектын имзалый һәм аны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә
Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән имзаланган карар проекты
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе Башкарма комитет карарын терки, тарату реестры нигезендә карарның күчермәсен җибәрә
Башкарма комитет карары
Район хакимияте белгече карарны гариза бирүчегә тапшыра
Гариза бирүчегә тапшырылган карар

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алу турында гражданнарның гаризаларын теркәү
КЕНӘГӘСЕ

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге

Башкарма комитетның ___________________________ районы хакимияте

Башланган_______________
Тәмамланган_____________

| Т/с | Гариза керүнең датасы һәм вакыты | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | Яшәү урыны | Исәпкә алу турында Башкарма комитет карары (датасы, номеры) | Исәпкә алуны кире кагу турында Башкарма комитет карары (датасы, номеры) | Кабул ителгән карар турында хәбәр итү кәгазе (хатның датасы, номеры)) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитетының
_________________________ районы хакимияте

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ сыйфатында исәпкә алу өчен гражданнардан документлар алуга

## Р А С П И С К А

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу максатында,
__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________,
(гариза бирүче гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)
түбәндәге документлар кабул ителде:

1. ____________________________________________________________
(документның исеме, номеры, датасы, битләр саны)
2. ____________________________________________________________
3. ____________________________________________________________
4. ____________________________________________________________

______________________________ ________________
______________________________
(гражданнарны исәпкә алу өчен җаваплы затның вазыйфасы) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

«____» ________________ 20___ел.

________________ ______________________________
(гариза бирүченең имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

«____» ________________ 20___ел.

Социаль файдаланудагы торак фондының
торак урыннарына наем килешүләре
буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ
гражданнарны исәпкә алу буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем килешүләре
буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу
К Е Н Ә Г Ә С Е

Яр Чаллы муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты

Башланган______________
Тәмамланган____________

| Т/с | Гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) | Гражданның теркәлү урыны адресы | Исәпкә алу турында Башкарма комитет карарының датасы, номеры | Исәпкә алуны кире кагу турында Башкарма комитет карарының датасы, номеры | Искәрмә (кабаттан теркәү датасы , өстәмә тапшырылган документлар исемлеге, аерым билгеләр) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 3 | 4 | 5 | 6 | 8 |
| | | | | | |
| | | | | | |

Кушымта
(белешмә)

Башкарма комитет районнары хакимиятләрендәге
муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы
вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Т/с | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Комсомол районы | | | |
| 1. | Хакимият Башлыгы | 70-34-27 | ikkr@mail.ru |
| 2. | Халык белән эшләү бүлекчә мөдире | 70-45-46 | ikkr@mail.ru |
| 3. | Әйдәүче белгеч | 70-04-32 | ikkr@mail.ru |
| Үзәк районы | | | |
| 1. | Хакимият Башлыгы | 47-55-33 | ispolkom_cr-nch@mail.ru |
| 2. | Халык белән эшләү бүлекчәсе мөдире | 47-55-72 | ispolkom_cr-nch@mail.ru |
| 3. | Әйдәүче белгеч | 47-55-73 | ispolkom_cr-nch@mail.ru |
| Автозавод районы | | | |
| 1. | Хакимият башлыгы | 56-50-71 | avtoispolcom@mail.ru |
| 2. | Халык белән эшләү бүлекчәсе мөдире | 32-98-39 | avtoispolcom@mail.ru |
| 3. | Әйдәүче белгеч | 56-74-16 | avtoispolcom@mail.ru |